

Мордовия мәгариф министрлыгы оештырган республикабыз ата-аналар жыелышына видеоэлемтә аша педагогларны, ата-аналарны, укучыларны борчыган сораулар тикшерелде, ә аларга жавапны чыгыш ясаган белгечләр бирде.

Һичшиксез, чарада катнашучылар фикерләv очен азык булган файдалы мәгълvмат алдылар. Шул ук конне, видеоэлемтәгә кадәр, 2нче Инсар урта мәктәбендә 9 һәм 11 нче сыйныф укучыларынын ата-аналары очен гомумрайон ата-аналар жыелышы булды. Анда шулай ук мәктәп директорлары һәм сыйныф житәкчеләре катнашты.
Чараны Инсар администра-циясенен социаль эш буенча идарә башлыгы Рауф Вәли улы Долотказин алып барды. Кон тәртибенә куелган «9, 11 сыйныф чыгарылыш укучыларынын дәvләт йомгаклау аттестациясе мәсьәләләре» буенча агымдагы елда районда ОГЭ һәм ЕГЭ vткәрvнен оештыру һәм vзенчәлекләре турында тулырак мәгълvмат бирелде. Ата-аналарнын йомгаклау аттестациясен vткәрv буенча алдан эшләv, имтиханнар, аларны vткәрv технологиясендәге vзгәрешләр турындагы сорауларына жаваплар бирелде.
Чыгарылыш  сыйныф укучыларынын ата-аналары очен генә тvгел, «Укучыларнын никотинлы катнашмалар куллануын профилактикалау» дигән чарада фикер алышкан икенче мәсьәлә дә актуаль иде. Бу житди проблема районда балигъ булмаганнар тарафыннан снюс һәм башка шундый куркыныч продукция куллануга кагылышлы хәл, әлеге афәткә каршы тору чаралары турында сойләделәр.
Аннан сон чаранын икенче олеше, әйтеп киткәнчә, республика ата-аналар жыелышында катнашу булды. Һичшиксез, фикерләv очен азык булган файдалы мәгълvматны чарада катнашучылар кvп алды.

Наилә НАСЫРОВА